СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

27.12.2024 № 53/6

На №__________от______________

# КАРАР

**2024 елга Тукай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фараз планын (программасын) үтәү нәтиҗәләре турында хисапны раслау хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы капиталь төзелеш хезмәте» муниципаль унитар предприятиесен үзгәртеп оештыруны фараз планына кертү турында» Советның 2023 елның 27 декабрендәге 41/4 номерлы карарына, Тукай муниципаль районы уставына таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елга Тукай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фараз планын (программасын) үтәү нәтиҗәләре турында хисапны әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров